РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ЧИСТОПОЛЬСКИЙ ГОРОДСКОЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЧИСТАЙ ШӘҺӘРЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

---

*Постановление* *Карар*

10.05.2023 Чистай шәһәре № 60

Чистай шәһәр Башкарма комитетының
2016 елның 27 июнендәге
«Стационар булмаган сәүдә
объектларын урнаштыру схемасын раслау турында»
96 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә сәүдә эшчәнлеген дәүләт тарафыннан җайга салу нигезләре турында»гы 2009 елның 28 декабрендәге 381-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының «Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнары тарафыннан стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында»гы 2011 елның 26 февралендәге 34-ОД номерлы боерыгын үтәү йөзеннән, «Муниципаль милектәге җирләрдә, яисә җир кишәрлекләрендә, шулай ук дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдә, яисә җир кишәрлекләрендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибен раслау турында»гы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 13 августындагы 553 номерлы, «Дәүләт милке чикләнгән җирләрдә, яисә җир кишәрлекләрендә, шулай ук дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдә, яисә җир кишәрлекләрендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибенә үзгәрешләр кертү турында»гы 2017 елның 18 сентябрендәге 675 номерлы карарларына таянып, Чистай шәһәре Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Чистай шәһәре Башкарма комитетының 2016 елның 27 июнендәге «Стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасын раслау турында»гы 96 номерлы карары белән расланган стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасына, Кушымта нигезендә, 111 - 116 пунктлар белән тулыландырып, өстәмәләр кертергә.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының рәсми сайтында (http://chistopol.tatar.ru/) урнаштырырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Чистай шәһәре Башкарма комитетының сәүдә, мәдәният, яшьләр сәясәте, спорт һәм туризм бүлеге баш белгече Әхмәтова Ю.Ю. йөкләргә.

Шәһәр Башкарма
комитеты җитәкчесе И.Ф. Рәхимов

Чистай шәһәре Башкарма комитетының
2023 елның 10 маендагы
60 номерлы карарына
Кушымта

Чистай муниципаль районының Чистай шәһәре территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасы

| № т/н | Стационар булмаган сәүдә объектының урнашу урыны | Сатыла торган товар ассортименты | Стационар булмаган сәүдә объекты төре | Сәүдә урыннары саны | Стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру вакыты |
|---|---|---|---|---|---|
| 111. | Чистай шәһәре, Кама елгасының «Наречье» шәһәр яр буе | Прокат | «Банан» су аттракционы | 1 | сезонлы |
| 112. | Чистай шәһәре, Кама елгасының «Наречье» шәһәр яр буе | Прокат | «Ватрушка» су аттракционы | 1 | сезонлы |
| 113. | Чистай шәһәре, Кама елгасының «Наречье» шәһәр яр буе | Прокат | «Лыжи» су аттракционы | 1 | сезонлы |
| 114. | Чистай шәһәре, Кама елгасының «Наречье» шәһәр яр буе | Прокат | Ятаклар, зонтиклар | 30 | сезонлы |
| 115. | Чистай шәһәре, Кама елгасының «Наречье» шәһәр яр буе | | «Спуск» су тавы | 1 | сезонлы |
| 116. | Чистай шәһәре, Кама елгасының «Наречье» шәһәр яр буе | | «Тарзанка» Аттракционы | 1 | сезонлы |